**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“29” март 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 29 мартында 10 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:

Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа торак пунктында гражданнар Җыенының 17.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү:

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Комыргуҗа авылында (территорияне чистарту-үлән чабу;Комыргуҗа авыл паркында газон чабу;агач кисү өчен бензопила сатып алу).

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау,техник хезмәт күрсәтү( Комыргуҗа авылында Тукай урамына юл салу өчен изелгән таш сатып алу(эш һәм хезмәт өчен түләү);урам юлларын кардан чистарту.

3. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау (Комыргуҗа авылы зираты территориясен чистарту, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).”

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 210 (ике йөздә ун ) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 124 (йөз егерме дурт) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 124 (йөз егерме дурт) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа торак пунктында гражданнар Җыенының 17.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү” :

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Комыргужа авылында (территорияне чистарту-үлән чабу;Комыргужа авыл паркында газон чабу;агач кисү өчен бензопила сатып алу).

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау,техник хезмәт күрсәтү( Комыргужа авылында Тукай урамына юл салу өчен изелгән таш сатып алу(эш һәм хезмәт өчен түләү);урам юлларын кардан чистарту.
3. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау (Комыргужа авылы зираты территориясен чистарту, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)."

мәсьәләсе буенча карарны таныраа.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргужа авыл җирлеге Комыргужа авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча  һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргужа авыл җирлеге башлыгы — Низамиев Ф.Ф.